КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 май г.Казань № 319

2024 елда авыр формада хроник авыру белән интегүче инвалид бала Д.А.Овезов белән И.И.Цыфаркина гаиләсенә социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль милкенә торак урын сатып алу максатларында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елда авыр формада хроник авыру белән интегүче инвалид бала Д.А.Овезов белән И.И.Цыфаркина гаиләсенә социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль милкенә торак урын сатып алу максатларында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 11 май, 319 нчы
карары белән расланды

## 2024 елда авыр формада хроник авыру белән интегүче инвалид бала Д.А.Овезов белән И.И.Цыфаркина гаиләсенә социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль милкенә торак урын сатып алу максатларында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2024 елда авыр формада хроник авыру белән интегүче инвалид бала Д.А.Овезов белән И.И.Цыфаркина гаиләсенә социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының (алга таба – муниципаль берәмлек) муниципаль милкенә торак урын сатып алуга чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар (алга таба шул ук эзлеклелектә – чара, башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган башка бюджетара трансфертлар белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Башка бюджетара трансфертлар 2024 елда әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

муниципаль берәмлекнең муниципаль милкенә сатып алынырга тиешле торак урын, торак урынны сатып алу кыйммәте күрсәтелгән чара турында мәгълүмат бирелгән, шул исәптән әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка бюджетара трансфертларны тоту тәртибе каралган, билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән муниципаль хокукый акт (алга таба – муниципаль хокукый акт) булу;

әлеге Тәртипнең 12 пункты нигезендә тулы күләмдә финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча муниципаль берәмлек йөкләмәсе күздә тотыла торган башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү һәм килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе – Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Осиново авылы чикләрендә кимендә 18 кв.метр өстәмә мәйданлы кимендә 42 кв.метр мәйданлы торак урынны муниципаль берәмлекнең муниципаль милкенә сатып алу.

6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявка (алга таба – заявка);

вәкаләтле зат тарафыннан расланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында тулы күләмдә финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган агымдагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының кабул ителгән карарыннан өземтә;

муниципаль хокукый актның таныкланган күчермәсе;

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән таләпләрне үтәп, муниципаль берәмлекнең муниципаль милкенә торак урын сатып алу турында хокук ияләре белән төзелгән килешүләрнең таныкланган күчермәләре.

7. Муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органына Министрлыкка дөрес булмаган мәгълүмат биргән, шул исәптән түбәндәгеләр өчен җаваплылык йөкләнә:

муниципаль берәмлекнең муниципаль милкенә торак урын сатып алу турында кабул ителгән карарларның нигезлелеге;

заявкадагы мәгълүматларның дөрес булмавы;

муниципаль берәмлекнең муниципаль милкенә сатып алынырга тиешле торак урын бәясенә йогынты ясый торган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

8. Әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлык тарафыннан алар кергән көнне теркәлә.

9. Министрлык әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә заявканы карап тикшерә һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында йә башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органына карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә хәбәр итә.

10. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының үтәлмәве;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

11. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга башка бюджетара трансфертлар бирү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондыннан бүлеп бирелә торган акча күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнә.

12. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс

министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасы нигезендә Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы арасында төзелә торган килешү буенча бирелә.

13. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе;

муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапларны тапшыру формасы һәм сроклары;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең билгеләнгән нәтиҗәсенә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлектәге вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан Килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану йөкләмәләре үтәлүен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

якларның килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

14. Муниципаль берәмлек бюджетының тулы күләмдә финанслашу өчен башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләме, башка бюджетара трансфертлардан бирү нәтиҗәсенең килешүдә билгеләнгән мәгънәсенә ирешү зарурлыгыннан чыгып, муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар белән раслана (җыелма бюджет исемлегендә билгеләнә).

15. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына күчерелә.

16. Муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисапны килешүдә каралган срокларда тапшыра.

Планлаштырылган чаралар үтәлмәгән очракта, хисапларга теркәлә торган аңлатма язуында үтәлмәү сәбәпләре һәм муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителгән чаралар турында мәгълүмат бирелергә тиеш.

17. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән күрсәткечләрен

чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла.

18. Муниципаль берәмлек тарафыннан 2024 елның 31 декабренә карата килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, башка бюджетара трансфертлар 2025 елның 1 мартына кадәр муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

19. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан әлеге Тәртипнең 18 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына акча кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

20. 2025 елның 1 гыйнварына карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2025 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемене күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемене түләтелергә тиеш.

21. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

22. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен законнар нигезендә җаваплы.

Башка бюджетара трансферттан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча  законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

23. Башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

---